СОВЕТ НОВОКИНЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

улица Советская, д.10, с.Новый Кинер,
Арский муниципальный район, 422031

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ

СОВЕТЫ

Совет урамы, 10 нче йорт, Яңа Кенәр
авылы, Арча муниципаль районы, 422031

Тел.,факс (84366)9-12-65, (84366)9-12-68, 9-12-60. E-mail: Nkin.Ars@tatar.ru

**Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**« 03 » апрель 2026 ел** **№ 26**

## Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кенәр авыл җирлеге Советының норматив хокукый актларын Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Яңа Кенәр авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

- “Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау турында” 2023 елның 17 февралендәге 96 номерлы карар;
- “Яңа Кенәр авыл җирлегенең “Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау турында” 2023 елның 17 февралендәге 96 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында” 2023 елның 19 маендагы 110 карары.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы Ә.Ә.Гайфуллин